ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» октября 2024 ел № 277

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы өстәмә белем бирүнең муниципаль бюджет учреждениеләрендә физик (юридик) затларга түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 10.11.2020 елның 359 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы «Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмалары тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында регламентны раслау хакында» 06.05.2014 елның 2556/14 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль бюджет өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләрендә физик (юридик) затларга түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 2020 елның 10 ноябрендәге 359 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (2023 елның 29 сентябрендәге 298 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы муниципերҗе муниципаль районы «Радуга талантов»Балалар иҗаты йорты» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең чик тарифларын әлеге карарга кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz/tatarstan/ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan/ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 15.10.2024 елның 277
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы өстәмә белем бирүнең муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең иң чик тарифлары**

| Т/с | Хезмәтнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум, бер берәмлек өчен. | Айда дәреслә р саны | Хезмәт күрсәтү бәясе, айга, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| **Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Радуга талантов» балалар иҗаты йорты» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе** | | | | | |
| 1 | 5-17 яшьлек балалар өчен “Картинг” өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча укыту | Академик сәгать 40 минут | 260,0 | 8-10 | 2080,0-2600,0 |
| 2 | 7-12 яшьлек балалар өчен чит телләрне тирәнтен өйрәнү буенча өстәмә гомуми белем бирү программалары (инглиз, француз телләре) буенча белем бирү | Академик сәгать 40 минут | 50,00 | 16-18 | 800,0-900,0 |
| 3 | 4 яшьлек балалар өчен «Оста куллар», «иртә үсеш мәктәбе» өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча укыту | Академик сәгать 40 минут | 80,0 | 16-18 | 1280,0-1440,0 |
| 4 | Өлкәннәр өчен сәламәтләндерү чараларын оештыру сәламәтлекне ныгыту буенча төрле секцияләр, төркемнәр | 60 минут | 200,0 | 8-9 | 1600,0-1800,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (гимнастика, аэробика, ритмика, чаңгыда шуу, спорт уеннары, гомумфизик әзерлек һ. б.) булдыру. | | | |
| 5 | Конкурслар, чаралар, фестивальләр, мастер-классслар, семинарлар, методик күргәзмәләр, турнирлар, иртәнге бәйрәмнәр, уен программалары, мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары, балалар һәм өлкәннәр өчен бәйрәмнәр һәм ярышлар оештыру һәм үткәрү | Чара (60 минут) | | Килешү буенча |
| 6 | Балалар өчен күчмә чаралар оештыру | Чара (60 минут) | | Килешү буенча |
| 7 | Өлкәннәр өчен күчмә корпоратив кичә оештыру | Чара (60 минут) | | Килешү буенча |
| 8 | Документларны сканерлау, күчереп язу, бастырып чыгару хезмәтләре күрсәтү | 1 бит | 10,0 | |
| 9 | Төсле принтерда басма | 1 бит | 20,00 | |
| 10 | Ламинацияләнгән документлар | бит | 40,00 | |
| 11 | Костюмнар прокаты | 1 шт./тәүлек | 200,00 | |
| 12 | Картинглар прокаты | 1шт/10 минут | 300,00 | |
| 13 | Төркемле дәресләр уздыру өчен зал бирү | 60 минут | 500 | |